ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БУГУЛЬМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.06.2021 г. Бугульма № 206

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитетының «административ комиссиясен төзү турындагы " 2021 елның 1 мартындагы 109 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

№ 144-ТРЗ " Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» дип аталган 2005 елның 30 декабрендә кабул ителгән Татарстан Республикасы законы нигезендә

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Бөгелмә муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» 2021 елның 1 мартындагы 109 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.2. 2 нче кушымтада:

- - 2.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ комиссия рәисе рәис урынбасары һәм административ комиссиянең җаваплы секретаре арасында вазыйфаларны бүлә, аларның функцияләрен Татарстан Республикасы Законы белән бирелгән вәкаләтләр чикләрендә билгели;

- 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ хокук бозулар турындагы эшләр административ комиссия утырышларында карала. Административ комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында карар аның Рәисе тарафыннан, ә аның булмаганда – рәис урынбасары тарафыннан кабул ителә. Карар Рәис карары белән, ә аның булмаганда – рәис урынбасары тарафыннан раслана. Утырышлар административ хокук бозулар турында беркетмәләр һәм башка материаллар кергән саен, әмма атнасына кимендә бер тапкыр үткәрелә»;

- 3.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ комиссиянең җаваплы секретаре рәис урынбасарына һәм комиссия әгъзаларына административ комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында административ комиссия утырышына кадәр кимендә өч эш көне кала күрсәтмә җибәрә.»;

- 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ комиссия утырышында катнашу мөмкин булмаган очракта, рәис, рәис урынбасары һәм комиссия әгъзалары бу хакта административ комиссия утырышы уздырылган көнгә кадәр бер эш көненнән дә ким булмаган вакыт эчендә административ комиссиянең җаваплы секретаренә хәбәр итәргә тиешләр.».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы «Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртиптә басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

А.М. Гершиков

Кушымта

Татарстан Республикасы Бөгелмә
муниципаль районы Башкарма комитеты
карары
______________ел. №_______

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының административ комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| ГЕРШИКОВ<br>Артур Михаил улы | Комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| МАСАЛИМОВ<br>Руслан Мэлс улы | Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитеты рәисе урынбасары, Эшләр идарәчесе |
| АСТАШИНА<br>Оксана Юрий кызы | Административ комиссиянең җаваплы сәркатибе, Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитетының баш белгече |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| НИГМАТУЛЛИНА<br>Гөлфия Җәүдәт кызы | Бөгелмә муниципаль районы Советы Аппаратының җирле үзидарә органнары һәм территориаль органнар белән эш оештыру бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| ПОЛЕТАЕВА<br>Эльвира Рамил кызы | Бөгелмә муниципаль районы Советы Аппаратының Хокук бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы, Бөгелмә муниципаль районы Советы Аппаратының Хокук бүлеге баш белгече (килешү буенча) |